**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Колбай-Мораса ав. | **КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Кече Колбай-Мораса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 5 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Полевая урамы буенча 39нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Кече Колбай-Мораса авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Кече Колбай - Мораса авылы Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы һәм Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Кече Колбай-Мораса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- Кече Колбай –Мораса авылы торак пункты чикләрендә тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау;

- Кече Колбай –Мораса авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм сезонлы карап тоту.

««РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин